| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2022 Ябалак авылы № 5

Татарстан Республикасы Кайбычмуниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү турында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юлларыһәмюлэшчәнлегетурындаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүхакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Юл хәрәкәтеиминлегетурында» 196-ФЗ номерлы1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү, автомобиль юлларыннанфайдаланучыларгакүрсәтеләторганхезмәтләрнеңсыйфатынарттырумак сатларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетыКАРАР ИТӘ:

1.Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү турындагы нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең http:// ebalak-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.

ТатарстанРеспубликасы
Кайбычмуниципаль районы
Ябалак   авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022елның 14 апрелендәге
5 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларның файдалана алуын тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә, автомобиль юллары турындагы мәгълүматка, аларның торышы, эчтәлеге һәм ремонты турындагы мәгълүматка кагыла.

2. Мәгълүмат белән тәэмин итүнең төп принциплары түбәндәгеләр:

мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

мәгълүматның дөреслеге һәм аны вакытында тапшыру;

мәгълүматэзләү, алу, тапшыруһәмтаратуиреге.

3. Мәгълүмат белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Кайбычмуниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мәгълүмат бирү түбәндәге мәсьәләләр буенча тәэмин ителә:

4.1. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары маршрутлары турында.

4.2. Траннспорт чараларының тиешле участокларда юл хәрәкәте куркынычсыз шартлары турында.

4.3. Автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату шартлары һәм сроклары һәм аларны йөреп чыгу мөмкинлегеннән файдалану турында.

4.4. Транспорт чараларының хәрәкәт тизлеге турында.

4.5. Түләүле нигездә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлыннан яисә мондый автомобиль юлы участогыннан түләүле нигездә файдалану турында һәм алар буенча транспорт чаралары йөрү бәясе турында, алар буенча күрсәтелә торган хезмәтләр турында, аларның түләү тәртибе, рәвешләре һәм системасы турында, мондый автомобиль юлы яисә мондый участок буенча транспорт чаралары йөрү бәясенә керә торган хезмәтләр исемлеге турында, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге гомумифайдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлы буенча транспорт чараларының альтернатив түләүсез йөрү мөмкинлеге турындакарар кабул итү турында.

4.6. Бер күчәргә исәпләгәндә мөмкин булган йөкләнеш турында.

4.7. Кирәкле очракларда юлныре конструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау фактлары һәм сроклары турында.

5. Татарстан Республикасы Кайбычмуниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

5.1. Татарстан Республикасы Кайбычмуниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында дөрес мәгълүм аталырга.

5.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүматтан файдалану хокукын боза торган җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның һәм (яисә) гамәлләрен (гамәлкылмавын) билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирлеә һәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге түбәндәге ысуллар белән тәэмин ителә:

6.1. Массакүләм мәгълүмат чаралары матбугат басмаларында мәгълүматны бастырып чыгару.

6.2. Мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру.

6.3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге автомобиль юлларының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге бүленгән полосаларында һәм юл буе полосаларында, биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның һәм башка техник чараларының конструктив элементларында, шулайук җәмәгать транспорты хәрәкәтенең тукталыш пунктларында урнашкан һәм тотрыклы территориаль урнашуның мәгълүмат такталарында, стендларында, билгеләрендә һәм башка техник чараларында мәгълүма турнаштыру.